КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 30 март г.Казань № 197

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 22 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 29 декабрь, 666 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 23 декабрь, 1005 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Бер тапкыр бүләкләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата хезмәт хакы составына кертелә:

вазыйфаи оклад;

классльі чин өчен оклад;

дәүләт хезмәтенең махсус шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәре үлгән очракта аның гаиләсенә бер тапкыр бирелә торган түләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 20 гыйнвар, 15 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәре үлгән очракта аның гаиләсенә бер тапкыр бирелә торган түләү

тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

6 нчы пунктның тугызынчы абзацындагы «дәүләт хезмәткәре үлеменә кадәр кимендә 6 ай алдан билгеләнгән күләмдә» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин